

## ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯ СӘХИБҖАМАЛ ГЫЙЗЗӘТУЛЛА КЫЗЫ (1885—1974)

## ГИЗЗАТУЛЛИНА-ВОЛЖСКАЯ САХИБЖАМАЛ ГИЗЗАТУЛЛОВНА (1885—1974)

Казан шәһәрендә дөньяга килә. Хатын-кызлардан беренче татар артисткасы, милли театрга башлап нигез салучыларның берсе. Татар сәхнәсенең күренекле эшлеклесе. 1907 елда «Сәйяр» труппасында эшли башлый. 1912 елда Уфада «Нур» исемле икенче профессиональ татар труппасын оештыра һәм 1918 елга кадәр шунда артистка, режиссер, җитәкче була. Гражданнар сугышы елларында фронттагы театр бригадаларында хезмәт итә. Сугыш беткәч, Ижевск шәһәрендә яши. Гомеренең соңгы елларын Казанда үткәрә.

Гыйззәтуллина-Волжская татар театр мәктәбенә лирик-романтик юнәлеш алып килүче беренче карлыгач, ул мөселман дөньясында да иң беренче артистка. Әсәрнең үзәгендә торган яшь хатын-кыз рольләрен романтик рухта, зур дулкынлану, көчле темперамент белән калку итеп башкара.

Аның рольләре: Шәфыйка — «Кызганыч бала» (Һ. Камал), Бибиҗамал — «Хуҗа һәм приказчик» (А. Островский буенча), Гайни, Гайшә — «Бәхетсез егет», Сәрбиҗамал — «Уйнаш» (Г. Камал), Сәгадәт — «Мөсибәте Фәхретдин» (Н. Вәзиров), Гайшә — «Җиңел хезмәттә» (Ф. Ярыгин), Гөлҗиһан — «Надир шаһ» (Н. Нариманов), Зәйнәп — «Яшь хатын» (Д. Таждаров), Луиза — «Мәкер вә мәхәббәт» (Ф. Шиллер), Зөбәйдә — «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» (С. Рәмиев), Катерина — «Яшенле яңгыр» (А. Островский), Адриана — «Хөкемдә хаталык» (А. Деннери), Мәгърифә — «Оят» (Я. Вәли), Фатыйма — «Мин-минлек корбаны» (Лысенко-Коныч), Бибиҗиһан — «Бичара Бибиҗиһан» (З. Сәетзадә) һ. б.

ТАССРның атказ. арт.—1926 ел.

Родилась в Казани. Первая татарская и мусульманская актриса, одна из организаторов национального театра, режиссер. Выдающийся деятель татарской сцены. Пришла в театр, в труппу «Сайяр», в 1907 году. В 1912 году организовала вторую профессиональную труппу — «Нур», где была актрисой, режиссером, руководителем. В годы гражданской войны — участница фронтовых театральных бригад. После гражданской войны жила в Ижевске. Последние годы жизни прожила в г. Казани.

Гиззатуллина-Волжская — родоначальник лирико-романтического направления в татарской актерской школе. Она создавала образы лирических героинь, романтически взволнованных, эмоционально-темпераментных, возвышенных.

Ее роли: Шафика — «Бедное дитя» Н. Камала, Бибижамал — «Хозяин и приказчик» А. Островского, Гайни, Гайша — «Несчастный юноша» Г. Камала, Гайша — «На легкой работе» Ф. Ярыгина, Сагадат — «Горе Фахретдина» Н. Везирова, Гульджихан — «Надир шах» Н. Нариманова, Зайнаб — «Молодая жена» Д. Таждарова, Сарбижамал — «Разврат» Г. Камала, Луиза — «Коварство и любовь» Ф. Шиллера, Зубайда — «Живи, Зубайда, буду жить и я» С. Рамиева, Катерина — «Гроза» А. Островского, Адриана — «Судебная ошибка» А. Деннери, Магрифа — «Стыд» Я. Вали, Фатыма — «Жертва эгоизма» Лысенко-Коныча, Бибиджихан — «Бедная Бибиджихан» З. Саетзаде и др.

Засл. арт. ТАССР — 1926 г.

Источник: Артисты театра им. Галиаскара Камала: Библиографический справочник. – Казань: Татарское книжное издательство, 1996. – С.12-13